КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 30 гыйнвар г.Казань № 40

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 19 ноябрь, 1105 нче карары белән расланган Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 19 ноябрь, 1105 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 май, 490 нчы, 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы, 2022 ел, 18 ноябрь, 1235 нче, 2023 ел, 7 апрель, 429 нчы, 2024 ел, 13 март, 137 нче, 2024 ел, 29 август, 711 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге пунктында билгеләнгән

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 15 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.»;

23 пунктта:

беренче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

24 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктта билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең яңа версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

27 пунктта:

дүртенче абзацта «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә;

бишенче абзацта «шартнамәләр» сүзеннән соң «(килешүләр)» сүзен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин